СОВЕТ ИСКЕ-КАЗАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422730, Республика Татарстан, Высокогорский район
с. Куркачи, ул. Клубная, 4

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ-КАЗАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422730, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Коркачык авылы, Клуб ур., 4

Тел./факс: +7(84365) 70-700, e-mail:Ikaz.Vsg@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
«19» мая 2020 г.

КАРАР
№ 189

Иске-Казан авыл җирлеге Советының 2019 елның 11 ноябрендәге 173 нче номерлы «Җир салымы турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясенең Салым кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль закон нигезендә, «Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Иске-Казан авыл җирлеге Советының 2019 елның 11 ноябрендәге 173 нче номерлы «Җир салымы турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5. пунктта «салым түләүчеләр-оешмалар һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;
2) 5.1., 5.2 пунктларын «төшереп калдырырга»;
3) 7.1. пунктның 4 абзацтагы икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ташлама бирү өчен Бөек Ватан сугышы ветераны таныклыгы яки сугышта катнашучы таныклыгы, әлеге ташламаны алу хокукын раслаучы башка тиешле документлар нигез була»

4) 3 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 3.1.1. пункт белән тулыландырырга:

«3.1.1. Салымнар түләү салым түләүчеләр тарафыннан җир кишәрлекләре торган урында башкарыла.

Салым түләүче оешмалар өчен салым түләү беренче, икенче һәм өченче квартал тәмамланганнан соң, узган хисап чорыннан соң килә торган икенче айның 5 числосыннан да соңга калмыйча җир кишәрлегенең кадастр бәясенең процент өлешенең тиешле салым ставкасы ¼ күләмендә аванс түләүләре белән башкарыла.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталындагы рәсми сайтында: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. 3.1.1 пунктның икенче абзацы 2021 елның 1 гыйнвареннән үз көчен югалта.

. Әлеге Карар Россия Федерациясе Салым Кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

5. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе
Авыл җирлеге Башлыгы Г.Р.Закирова